TATAРСТАН

# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Татарстан Республикасы Нурлат районы һәм Нурлат шәһәре буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2010 елның 23 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Нурлат районы һәм Нурлат шәһәре буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре тасвирламасын әлеге Законга кушымта нигезендә расларга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан,Кремль
2010 елның 31 декабре
№ 108-ТРЗ

"Татарстан Республикасы Нурлат районы
һәм Нурлат шәһәре буенча Татарстан
Республикасы җәмәгать судьяларының
суд участоклары чикләре турында"
Татарстан Республикасы Законына
кушымта

**Татарстан Республикасы Нурлат районы һәм Нурлат шәһәре буенча**
**Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының**
**суд участоклары чикләре тасвирламасы**

## 1 нче суд участогы

1 нче суд участогы чигенә "Нурлат шәһәре" муниципаль берәмлегенең бер өлеше керә, аның чиге шәһәрнең көнбатыш чиге Сембер урамы белән кисешкән җирдә урнашкан ноктадан алып, так якта урнашкан йортларны кертеп, Сембер урамының һәм, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Совет урамының күчәр сызыклары буйлап Нурлат районына 70 ел урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба борыла һәм, уң якта (Гыйматдинов урамы буйлап) урнашкан оешмаларны һәм предприятиеләрне кертеп, Нурлат районына 70 ел урамы буйлап Нурлат урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, аннары, уң якта урнашкан территорияне кертеп, Нурлат урамы буйлап төньяк-көнчыгышка таба шәһәрнең көнчыгыш чигенә кадәр уза, алга таба "Нурлат шәһәре" муниципаль берәмлеге чиге буйлап көньяк-көнчыгышка таба шәһәрнең көнбатыш чиге Сембер урамы белән кисешкән җирдә урнашкан ноктага кадәр бара.

1 нче суд участогы чигенә түбәндәге муниципаль берәмлекләр территорияләре керә: Нурлат муниципаль районының Әмзә, Андреевка, Биккол, Богдашкино, Киекле, Егоркино, Колбай-Мораса, Мамык, Яңа Иглай, Сәләнгеш, Урта Камышлы, Иске Чаллы һәм Төрнәс авыл җирлекләре.

## 2 нче суд участогы

2 нче суд участогы чигенә "Нурлат шәһәре" муниципаль берәмлегенең бер өлеше керә, аның чиге шәһәрнең көнчыгыш чиге Нурлат урамы белән кисешкән җирдә урнашкан ноктадан алып, уң якта урнашкан территорияне кертеп, Нурлат урамы буйлап көньяк-көнбатышка таба Нурлат районына 70 ел урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба, уң якта (Нурлат районына 70 ел урамы буйлап) урнашкан йортларны кертеп, Нурлат районына 70 ел урамы буйлап көньяк-көнчыгышка таба Совет урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба, так якта урнашкан йортларны кертеп, Совет урамының күчәр сызыгы буйлап көнбатышка таба уза, аннары, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Сембер урамы күчәре буйлап шәһәрнең көнбатыш чигенә кадәр бара, алга таба "Нурлат шәһәре" муниципаль берәмлегенең чиге буйлап төньяк-көнчыгышка таба шәһәрнең көнчыгыш чиге Нурлат урамы белән кисешкән җирдә урнашкан ноктага кадәр бара.

2 нче суд участогы чигенә түбәндәге муниципаль берәмлекләр территорияләре керә: Нурлат муниципаль районының Әхмәт, Биләркүл, Гәйтән, Ялаур, Заречный, Кычытканлы, Яңа Тумба, Иске Әлмәт, Би Күле, Тимерлек, Фома, Чулпан һәм Якушкино авыл җирлекләре.